**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**МӘГАРИФ ҺӘМ ФӘН МИНИСТРЛЫГЫ**

# ТАТАР ТЕЛЕ

## 21 код

Татар телендә башлангыч гомуми белем бирү оешмалары өчен

**2 нче вариант**

**Мәктәп______________________________________ 4 нче ___ сыйныфы**

**Фамилия, исем __________________________________________________**

*укучының фамилиясе, исеме*

## УКУЧЫ ӨЧЕН КҮРСӘТМӘ

Эшне башкару өчен 40 минут вакыт бирелә.

Биремнәр төрле авырлыкта. Бер төркем биремнәргә җавапны тәкъдим ителгән дүрт вариант арасыннан сайлап алып, аны түгәрәк эченә алырга кирәк. Икенче төркем биремнәрнең җавабын сүзләр белән язарга кирәк.

Җавапларыңны язганчы, биремне игътибар белән укы, яхшылап уйла.

Авыр тоелган биремнәрне калдырып тор, алдагы биремнәрне башкаруга күч. Вакытың калса, калдырып торган биремнәргә кабат кайта аласың.

Әгәр дә ялгыш җавап бирсәң, төзәтергә була. Моның өчен ялгыш җавабыңны пөхтә генә итеп сыз һәм үзең дөрес дип санаган җавабыңны яз.

Уңышлар телибез!

2014/2015 нче уку елы

**1.** Калын сузык авазлар гына чагылдырылган рәтнең санын түгәрәк эченә ал.

1) [а], [ы], [у], [о]
2) [а], [ы], [ү], [о]
3) [а], [ы], [у], [ө]
4) [а], [р], [у], [ө]

**2.** Фамилияләр алфавит тәртибендә язылган рәтнең санын түгәрәк эченә ал.

1) Яруллин, Хәсәнов, Әмирхан, Алиш
2) Алиш, Хәсәнов, Яруллин, Әмирхан
3) Алиш, Әмирхан, Хәсәнов, Яруллин
4) Алиш, Әмирхан, Яруллин , Хәсәнов

**3**. ***х*** хәрефе язылырга тиешле сүзне билгелә. Дөрес җавапны түгәрәк эченә ал.

1) мәш...үр 2) ...инд 3) мәр...әмәт 4) ...ичбер

**4.** ***Сабакташым*** сүзендә нинди сүзләр яшеренгән?

***Сабакташым:***________________________________________________________

**5.** Кушма сүзләрнең кайсыларында **ъ** (аеру билгесе) языла? Дөрес җавапны түгәрәк эченә ал.

1) кул..югыч 2) кул..баш
3) кул..язма 4) кул..тамга

**6.** Бирелгән сүзләр арасыннан ***авыр*** сүзенең синонимын табып яз.

***гүзәл, катлаулы, чибәр, кыен, читен, җиңел, ямьсез, нәфис, котсыз, рәхәт.***

**7.** Алмашлык җөмләдә тәмамлык булып килгән очракны билгелә. Дөрес җавапны түгәрәк эченә ал.

1) Алар бүтән килмәделәр.

2) Тиздән көннәр җылына.

3) Синең рәсем ясыйсың киләме?

4) Һәркем үзенчә эшләде.

**8.** Капма-каршы мәгънәле сүзләр ничек атала? Дөрес җавапны түгәрәк эченә ал.

1) күпмәгънәле 2) аваздаш 3) омоним 4) антоним

**9.** Күрсәтү алмашлыгын билгелә. Дөрес җавапны түгәрәк эченә ал.

1) кайсы 2) безнеке 3) һәрбер 4) теге

**10.** Исем - җөмләдә хәбәр булып килгән очракны билгелә. Дөрес җавапны түгәрәк эченә ал.

1) Фәннең башы – акыл.

2) Әни эштән иртә кайтты.

3) Сабантуйга да озак калмады.

4) Казанлылар туган шәһәрләре белән горурлана.

**11.** Тамырдаш сүзләр арасында артык сүзне билгелә. Дөрес җавапны түгәрәк эченә ал.

1) кар 2) карлы 3) карсыз 4) карал

**12.** ***Язмышларны*** сүзенең төзелеше кайсы рәттә дөрес күрсәтелгән? Дөрес җавапны түгәрәк эченә ал.

1) яз – мы –ш-лар-ны

2) яз –мыш – ла-р-ны

3) язмыш-лар-ны

4) язмыш- ларны

**13.** Килгән кунакны өйгә чакыру сүзләрен билгелә. Дөрес җавапларны түгәрәк эченә ал.

1) Гаепләп китмәгез инде.

2) Хуш киләсез!

3) Хәерле юл!

4) Рәхим итегез, түрдән узыгыз!

**14.** Җөмләдә ассызыкланган сүз нинди сүз төркеменә карый?

***Җирән Кашканың сүзен атлар ишеткәннәр, <u>ләкин</u> кайберләре тыңламаган.***

1) бәйлек

2) кисәкчә

3) теркәгеч

4) рәвеш

**15.** Бәйлекләрдән торган рәтне билгелә.

1) ләкин, әгәр, чөнки

2) өчен, белән, гына

3) астыннан, янында, юлында

4) таба, өчен, чаклы

**16.** Хикәя фигыльләрнең төрләнеше дөрес күрсәтелгән рәтне билгелә.

1) заман, барлык, дәрәҗә

2) килеш, зат, барлык-юклык

3) заман, зат-сан, барлык-юклык

4) килеш, сан, дәрәҗә

**17.** 1 нче зат, берлек сан, иялек килешендәге алмашлыкны тап һәм билгелә:

1) минем 2) миңа 3) безнең 4) минеке

**18.** Әйтемнәрдә төшеп калган сүзне җәяләр эчендә бирелгән вариантның берсен сайлап алып, тиешле урыннарына яз.

1) ______________белгәнен эшләр, ________________ бармагын тешләр. *(Белмәгән, белгән)*

2) _____________кеше – күргәнен, _______________ – ашаганын сөйләр. (*Галим, надан)*

**19.** Фикер йөртү тибындагы текстны тулыландыр.

*Җөмләнең баш кисәкләрен билгеләгәндә, мин болай фикер йөртәм. Башта хәбәрне табам, аны табуы җиңел, гадәттә, ул җөмләнең________________ була. Хәбәрдән кем? нәрсә? сорауларын куям. Шундый сорауларга җавап бирүче сүзләр эшне, хәлне, хәрәкәтне______________ белдерә. Димәк, бу сүз – җөмләнең* __________ *була* .

**Сиңа кирәкле сүзләр:** *башкаручыны, иясе, азагында*

**20.** Билгеләнгән сүз җөмләнең нинди кисәге? Дөрес җавапны түгәрәк эченә ал.

***Ул безгә килергә <u>берсүзсез</u> риза булды.*** *(А.Шамов)*

1) аергыч
2) тәмамлык
3) хәл
4) хәбәр